**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## 2020 елны Татарстан Республикасында Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү елы дип игълан итү турында

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү, республиканың төзелүендә һәм үсешендә мөһим тарихи чорга җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү максатларында **карар бирәм:**

1. 2020 елны Татарстан Республикасында Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү елы кысаларында чаралар әзерләүне һәм уздыруны Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетына йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтү елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 25 сентябрь
№ ПУ-572

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ